**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**МЕНДЕЛЕЕЛЕЕВСКИЙ**
**ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**
**МЕНДЕЛЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК ШӘҺӘР**
**СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

12.08.2022 ел №37

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2007 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының шәһәр Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2021 елның 25 февралендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru/ һәм расланган документны Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.
3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының икътисад, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Советы Рәисе урынбасары Л.Р. Кривилева